**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

---

2026 елның 2 марты                                                  20 -РС номер

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитеты структурасын раслау турында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2011 елның 18 февралендәге 36-РС номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2023 елның 8 ноябрендәге 117-РС номерлы карары белән расланган «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасының Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру структурасын камилләштерү максатларында «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты структурасын раслау турында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2011 елның 18 февралендәге 36-РС номерлы карарына (соңгы үзгәрешләре белән 2025 елның 11 июлендәге 48-РС номерлы) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) төзелеш, ТКХ һәм торак фондын исәпкә алу бүлеген ТКХ һәм торак фондын исәпкә алу бүлеге итеп үзгәртергә;

2) архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеген төзелеш, архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге дип үзгәртергә.

2. Структур бүлекчәләр башлыкларына әлеге карарга кул куелган көннән алып бер ай эчендә ТКХ һәм торак фондын исәпкә алу бүлеге, төзелеш, архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге турында нигезләмә әзерләргә һәм Башкарма комитет җитәкчесенә раслауга тапшырырга, бүлекчәләр хезмәткәрләренең вазыйфаи инструкцияләрен әзерләргә.

3. 2026 елның 4 маеннан әлеге карарның 1 бүлегендә каралган үзгәрешләрне гамәлгә кертергә.

4. Үзгәрешләр нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты структурасын яңа редакциядә кушымта нигезендә расларга.

5. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Р. Т. Гарифуллинга йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**

Лаеш муниципаль районы Советының
2026 елның _ -номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты структурасы**

| № | Вазыйфа исеме | Берәмлекләр саны |
|---|---|---|
| 1. | Район Башкарма комитеты җитәкчесе | 1 |
| 2. | Район Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары | 1 |
| 3. | Район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары | 3 |
| 4. | Эшләр белән идарә итүче | 1 |
| 5. | Район Башкарма комитеты җитәкчесе ярдәмчесе | 1 |
| | Барлыгы: | **7** |
| **Торак-коммуналь хуҗалык һәм торак фондын исәпкә алу бүлеге** | | |
| 1. | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2. | Баш белгеч | 2 |
| 3. | Әйдәп баручы белгеч | 1 |
| | Барлыгы: | **4** |
| **Төзелеш, архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге** | | |
| 1. | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2. | Баш белгеч | 4 |
| 3. | Баш белгеч* | 1 |
| | Барлыгы: | **6** |
| **Мәдәният бүлеге** | | |
| 1. | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2. | Баш белгеч | 1 |
| | Барлыгы: | **2** |
| **Архив секторы** | | |
| 1. | Сектор мөдире | 1 |
| 2. | Баш белгеч* | 1 |
| | Барлыгы: | **2** |
| **ЗАГС бүлеге** | | |
| 1. | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2. | Әйдәп баручы белгеч | 1 |
| | **Барлыгы:** | **2** |
| **Икътисадый анализ, бухгалтерлык исәбе һәм контракт эшчәнлеге бүлеге** | | |
| 1. | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2. | Әйдәп баручы белгеч | 2 |
| | **Барлыгы:** | **3** |
| **Юридик бүлеге** | | |
| 1. | Бүлек башлыгы | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 2. | Әйдәп баручы белгеч | 1 |
| 3. | Баш белгеч | 1 |
| | **Барлыгы:** | **3** |
| **Оештыру-гомуми бүлек** | | |
| 1. | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2. | Әйдәп баручы белгеч | 2 |
| 3. | Водитель | 4 |
| | **Барлыгы:** | **7** |
| **Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге** | | |
| 1. | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2. | Баш белгеч | 1 |
| 3. | Әйдәп баручы белгеч | 1 |
| | **Барлыгы:** | **3** |
| **Икътисад һәм эшкуарлык бүлеге** | | |
| 1. | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2. | Әйдәп баручы белгеч | 2 |
| | **Барлыгы:** | **3** |
| **ММЧ белән эшләү, мәгълүматлаштыру бүлеге һәм мәгълүматны яклау** | | |
| 1. | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2. | Баш белгеч | 2 |
| | **Барлыгы:** | **3** |
| **Опека һәм попечительлек бүлеге** | | |
| 1. | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2. | Әйдәп баручы белгеч | 2 |
| | **Барлыгы:** | **3** |
| **Балигъ булмаганнар эшләре буенча Комиссия** | | |
| 1. | Баш белгеч | 1 |
| 2. | Әйдәп баручы белгеч | 1 |
| | **Барлыгы:** | **2** |
| | **НИБАРЫ:** | **50** |

* Искәрмә: вазыйфа муниципаль хезмәт вазыйфасы булып саналмый

**Башлык урынбасары-**
**муниципаль район Советы**
**рәисе урынбасары** **Т.П. Борһанова**